**МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**14.03.2023** Казан **№ 104**

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 13 сентябрендәге 24 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатыннан, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 13 сентябрендәге 24 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының 2019 елның 24 маендагы 162 номерлы, 2021 елның 11 мартындагы 57 номерлы, 2021 елның 17 ноябрендәге 402 номерлы, 2022 елның 10 мартындагы 75 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба - Боерык) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары С. А. Мостафинага йөкләргә»;

Боерык белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәгә, 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«1.3. Иҗтимагый совет, үз эшчәнлегендә, Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә нигезләнеп эш итә.».

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Министр** **Р.Н.Садыйков**